**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты
карары**

**№794
15.02.2019**

Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган җәйге һәм кышкы чорда дүрт җәмәгать бәдрәфен карап тоту буенча хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 17 маддәсе, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезнамә, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган җәйге һәм кышкы чорда дүрт җәмәгать бәдрәфен карап тоту буенча хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ә. Кыямовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 15 февралендәге
794 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
«Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан
күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге (бер көн) | Чик тариф сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1. | «Тукай яр буе 1 чират» паркында кышкы чорда җәмәгать бәдрәфен карап тоту | сум | 4091,86 |
| 2. | «Тукай яр буе 1 чират» паркында җәйге чорда җәмәгать бәдрәфен карап тоту | сум | 3901,63 |
| 3. | «Тукай яр буе 2 чират» паркында кышкы чорда җәмәгать бәдрәфен карап тоту | сум | 4091,86 |
| 4. | «Тукай яр буе 2 чират» паркында җәйге чорда җәмәгать бәдрәфен карап тоту | сум | 3901,63 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова